ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 август 2024 ел № 5454

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2595 номерлы, 2023 елның 16 ноябрендәге 11212 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 1006 номерлы, 2024 елның 4 апрелендәге 2155 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә муниципаль программа чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Халыкны социаль тәэмин итү» 1003 бүлеге буенча каралган акчалар хисабына 637 763,2 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 227 547,29 мең сум; 2024 ел – 252 847,24 мең сум; 2025 ел – 157 368,67 мең сум.»;

2) 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел (мең сум) | 2024 ел (мең сум) | 2025 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорына барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 227 547,29 | 252 847,24 | 157 368,67 | 637 763,2 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | -»; |

- 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2023-2025 елларга программаны финанслау күләме 637 763,2 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Чор өчен барлыгы 637 763,2 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2023 ел – 227 547,29 мең сум;

2024 елга – 252 847,24 мең сум;

2025 елга – 157 368,67 мең сум.»;

- 6 бүлектә:

29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «29. | Муниципаль белем бирү оешмаларында укучы инвалид балаларны, сәламәтлеге буенча мөмкинлек ләре чикле балаларны, 3 һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү | Башкарма комитет | ел дәвамында | балалар саны | 6404 | 7300 | 7300 | 7300 | 129 000,00 | 146 723,11 | 48 382,54»; |

«барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы: | | | | 79606 | 116922 | 116971 | 116971 | 227 547,29 | 252 847,24 | 157 368,67». |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов